**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Бигеш авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

07.12.2023 ел **№ 122**

**Зәй муниципаль районы Бигешавыл җирлеге Советының 2014 елнын 14 ноябрендәге 197 нче номерлы «Бигеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында, шулай ук муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар тапшыру турында Нигезләмәне раслау хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 1 апрелендәге 90-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 28 сентябрендәге 86-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Зәй муниципаль районы Бигешавыл җирлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге Советы

**карар итте:**

1. Бигешавыл җирлеге Советының 2014 елның 14 ноябрендәге 197 нче номерлы карары белән расланган «Бигешавыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында, шулай ук муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар тапшыру хакындагы Нигезләмәгә (2021 елның 23 июлендәге 38 номерлы, 2022 елның 30 маендагы 65 номерлы каралары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 13 пунктта «,акцияләренең» сүзен төшереп калдырырга, «оешмаларнын)» сүзеннән соң «хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә

кадәр) цифрлы финанс активларын, цифрлы валютаны» сүзләре белән тулыландырырга;

1.2. 16 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Гражданның, муниципаль хезмәткә кергәндә, федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш, үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай ук хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирмәве яисә белеп ялган мәгълүмат бирү, күрсәтелгән гражданны муниципаль хезмәткә кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан, мондый мәгълүматьлар бирү мәҗбүри булган очракта, үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти белән бәйле бурычлары, шулай ук хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти белән бәйле бурычлары турында мәгълүмат бирмәү яисә белеп тулы булмаган мәгълүмат бирү, федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш, муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу була.

Муниципаль хезмәткәрләргә әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән дөрес булмаган мәгълүматларны тапшыру муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.»

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), торак пунктлар территориясендә махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Совет Рәисе** **И.Р.Вәлиев.**